РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**исполнительный комитет**
**Большесалтыковского сельского поселения**

422831, Республика Татарстан,
Камско-Устьинский район,
с. Б.Салтыки, ул.1 Мая, 26А
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы**
**муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

422831, Татарстан Республикасы,
Кама Тамагы районы,
Олы Салтык авылы, 1 Май урамы, 26А
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«24» октябрь 2025 ел** **№25**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Олы Салтык авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннары йөрү урыннарын билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә карата өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 елның 11 августы № 971нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклауны тәэмин итә торган йорт хайваннарын йөртү өчен шартлар тудыру максатларында, Олы Салтык авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Йорт хайваннарын йөртү өчен рөхсәт ителгән урын (урыннар) итеп билгеләргә:
- Олы Салтык авыл җирлегенең торак секторларыннан читтә гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре. (тиешле территориянең (җир кишәрлегенең (мәсәлән, торак секторлардан читтә, торак булмаган биналар янында урнашкан гомуми файдаланудагы территорияләр һ.б.) урнашкан урыны күрсәтелә.
2. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126;

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61;

- ТР , Кама Тамагы муниципаль районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Вафин